**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуганы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татар Шуганы авылы №114 «06» май 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2014 елның 08 августындагы 109 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (2015 елның 19 ноябрендәге 15 номерлы, 2016 елның 07 декабрендәге 47 номерлы, 2019 елның 23 апрелендәге 135 номерлы, 2020 елның 03 февралендәге 165 номерлы, 2021 елның 15 мартындагы 22 номерлы, 2021 елның 22 сентябрендәге 36 номерлы, 2023 елның 02 октябрендәге 94 номерлы, 2023 елның 09 октябрендәге 95 номерлы карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Татар Шуганы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2014 елның 08 августындагы 109 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (2015 елның 19 ноябрендәге 15 номерлы, 2016 елның 07 декабрендәге 47 номерлы, 2019 елның 23 апрелендәге 135 номерлы, 2020 елның 03 февралендәге 165 номерлы, 2021 елның 15 мартындагы 22 номерлы, 2021 елның 22 сентябрендәге 36 номерлы,

2023 елның 02 октябрендәге 94 номерлы, 2023 елның 09 октябрендәге 95 номерлы карарлар редакциясендә) 4.1 бүлегенең 1 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яисә) белешмәләр тапшыру.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рэис Хэертдинов М.Ш.